Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Клементейкино авыл җирлегенең
Багряж авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең Багряж авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Клементейкино авыл җирлегенең Багряж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Багряж авылы зираты өчен вагон-йорт сатып алу?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын ФАП бинасы янында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 24Б йорты.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Клементейкино
авыл җирлеге башлыгы Л.Э. Языков